«Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары,
Бөтендөнья татар конгрессының
Милли Шура Рәисе

_______________ В.Г. Шәйхразыев
_10 март_ 2026 ел

**Габдулла Тукайның 140 еллыгына багышланган «Без Тукайлы халык!» исемле халыкара шигърият бәйгесе**

# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге Нигезләмә Габдулла Тукайның 140 еллыгына багышланган «Без Тукайлы халык!» исемле халыкара шигърият бәйгесен (алга таба – Бәйге) оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.
1.2. Бәйгенең оештыручысы – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты.

## 2. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары

2.1. Бәйгенең максаты – татар телен, әдәби мирасыбызны пропагандалау, саклау һәм үстерү, Габдулла Тукайның иҗади мирасын популярлаштыру.
2.2.Бәйгенең төп бурычлары - сәнгатьле татар сөйләме күнекмәләрен үзләштерү, татар әдәбиятына кызыксыну уяту.

## 3. Бәйгене үткәрү тәртибе

3.1.Бәйгедә катнашучы оештыручыларга Габдулла Тукайның сәнгатьле итеп сөйләнгән бер әсәрен видеога төшереп, гариза белән бергә Tukay140@mail.ru электрон адресына җибәрергә тиеш.

3.2. Бәйгенең уздыру этаплары:
3.1.1. Беренче этап: Бәйге эшләрен кабул итү – 2026 елның 10 мартыннан 1 апреленә кадәр.
3.1.2. Икенче этап: жюри утырышы – 2026 елның 2 апреленнән 10 апреленә кадәр. Жюри әгъзалары Бәйгегә кабул ителгән эшләрне бәяли һәм ачык тавыш бирү юлы белән җиңүчеләрне билгели. Жюри карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.
3.1.3. Өченче этап: җиңүчеләрне игълан итү һәм бүләкләү – 2026 елның 6 апреленнән 30 апреленә кадәр,

## 4. Бәйгедә катнашучыларга таләпләр

4.1. Бәйгедә катнашу бушлай һәм ирекле.
4.2. Бәйгедә катнашу буенча яшь чикләүләре юк.
4.3. Бәйгедә Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүчеләр катнаша ала.
4.4. Бәйгедә катнашу автомат рәвештә катнашучының Бәйге шартлары белән таныш булуын һәм алар белән тулысынча риза булуын күз алдында тота. Әлеге нигезләмә Бәйгедә катнашучыларның барысы өчен дә расланган һәм мәҗбүри булып тора.
4.5. Бәйгедә катнашучының 2006 елның 27 июлендә кабул ителгән 152-ФЗ номерлы "Шәхси мәгълүматлар турында"гы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларын танышу, мәгълүмати һәм реклама максатларында кулланырга ризалык бирүен күз алдында тота. Шәхси мәгълүматлар Бәйгенең уздырылу вакыты дәвамында, шулай ук Бәйге тәмамланганнан соң да, мондый ризалыкны кире алганчы кулланыла.

## 5. Бәйге материалларын тапшыруга һәм әзерләүгә таләпләр

5.1. Гариза әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән кушымта формасы буенча тапшырыла.
5.2. Видеога таләпләр: 1920*1080, 16.9 (горизонталь рәвештә), mpg, mpeg2 яки mpeg4 (H264) форматында.

## 6. Оештыручының бурычлары һәм хокуклары

6.1. Оештыручының бурычлары:
– Бәйгене үткәрүне оештыру;
– Бәйгенең жюри составын формалаштыру һам жюри эшен тәэмин итү;
– Бәйгене үткәрүнең билгеләнгән тәртибен саклауны тәэмин итү;
– Барлык катнашучылар өчен бертигез шартлар булдыру;
– Бәйгедә катнашу өчен гаризалар кабул итү;
– Бәйгедә катнашу өчен җибәрелгән гаризаларның, эшләрнең әлеге нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү;
– Тәкъдим ителгән гаризаның әлеге нигезләмә таләпләренә туры килмәү очраклары ачыкланса, гаризаны теләсә кайсы этапта кире кагу;
– Катнашучылар турындагы мәгълүматларның конфиденциальлеген саклауны тәэмин итү;
– Бәйгенең документациясен алып бару, йомгаклау документларын рәсмиләштерү;
– Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү;
– Комиссиягә һам массакүләм мәгълүмат чараларына Бәйгенең барышы турында оператив мәгълүмат бирү;
– Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыру.

6.2. Оештыручының хокуклары:

– Бәйгенең уздырылу вакытын үзгәртү;

– Бәйгедә җиңүчеләр турындагы мәгълүматны һам аларның чыгышларын үз теләге буенча барлык массакүләм мәгълүмат чараларында һам социаль челтәрләрдә урнаштыру.

## 7. Нәтиҗәләр чыгару, катнашучыларны һәм җиңүчеләрне бүләкләү

7.1. Бәйгедә катнашкан һәр кешегә катнашучы дипломы юлланачак.

7.2. Бәйге җиңүчеләре җиңүче дипломнары һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнәчәк.

7.3. Бәйгегә иҗади якын килгән (видеоларны Г.Тукай белән бәйле истәлекле урыннарда, һәйкәлләре янында, төбәкнең танылган җирлекләре һәм объектлары каршында яздырган һ.б.) катнашучыларга аерым игътибар биреләчәк.

**Гариза үрнәге** (образец заявки)

| № | Исем, фамилия, әтисенең исеме (Ф.И.О.) | Туган көне, елы (дата рождения) | Эш/уку урыны (место работы/учебы) | Укылган әсәрнең исеме (название читаемого произведения) | Контактлар: ил, регион, шәһәр, моб.тел, эл.почта (контактные данные) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |